ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.05.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1149**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 354 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының салым йөкләнешен киметү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 354 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә үзгәрешләр кертергә, аерым алганда, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенең 3 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә әлеге карарны ведомство карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләр 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Җитәкче урынбасары – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев